| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«30» январь 2023г. № 18

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 10 ноябрендәге 530 номерлы «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнелә торган Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнелә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарының 1 кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 сентябрендәге 987 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, район халкының тормыш сыйфатын күтәрү максатларында һәм Теләче муниципаль районы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф ставкаларын (окладларын) күтәрү зарурлыгына бәйле рәвештә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 10 ноябрендәге 530 номерлы «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнелә торган Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» карарының (район Башкарма комитетының 14.10.2016 № 956, 17.10.2017 № 632, 31.01.2018 № 61, 02.03.2022 № 29 карарлары редакциясендә) 1 номерлы кушымтасына үзгәреш кертергә, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның 10 декабрендәге
530 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәре өчен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тарифлы ставкалар (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 15279 |
| 2 | 1,0159 | 15522 |
| 3 | 1,0323 | 15773 |
| 4 | 1,0480 | 16012 |
| 5 | 1,0656 | 16281 |
| 6 | 1,0827 | 16543 |
| 7 | 1,1010 | 16822 |
| 8 | 1,1187 | 17093 |
| 9 | 1,1363 | 17362 |
| 10 | 1,1553 | 17652 |
| 11 | 1,1736 | 17931 |
| 12 | 1,1933 | 18232 |
| 13 | 1,2129 | 18532 |
| 14 | 1,2325 | 18831 |
| 15 | 1,2528 | 19142 |
| 16 | 1,2738 | 19462 |
| 17 | 1,2947 | 19782 |
| 18 | 1,3163 | 20112 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.